ХӨКҮМӘТ ЙОРТЫНДА

финансчылар хисап тотты

> 2

КАДЕРЛЕБЕЗ ИДЕ...

Хезмәттәшебез Зимфира Гыйльметдинова белән хушлашу

> 3

МӘДӘНИ ТУКТАЛЫШ

Китап укыр өчен ресторанга чакыралар

> 4

ГАИЛӘ УЧАГЫ

Апа-сеңел арасындагы якынлык бөтен гаиләгә үрнәк булып тора

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 185 (28767) | Шимбә | 18 декабрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

АТТА ДА, ТӘРТӘДӘ ДӘ

ЮЛ ФАҖИГАЛӘРЕ КИЛЕП ЧЫГУГА КЕМ ГАЕПЛЕ?

Быел республика юлларында 276 кешенең гомере өзелгән. Хөкүмәт йортында Министрлар Кабинеты һәм Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы коллегиясенең юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча уртак утырышында әнә шул санны киметү турында сөйләштеләр. Балаларның иминлеген кайгырту, булачак йөртүчеләрне әзерләүгә аерым игътибар бирделәр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстан буенча эчке эшләр министры Артем Хохорин әйтүенчә, узган ел белән чагыштырганда республика юлларында гомерләре өзелгән балалар саны быел ике тапкыр диярлек арткан. Узган ел Татарстан юлларында 8 бала үлгән булса, быел әлеге куркыныч сан 14кә җиткән. «Бу күренешкә борчылмый хәлең юк. Балалар бу хәлгә берничек тә йогынты ясый алмый бит. Пассажир балаларның күбесе исерек килеш рульгә утырган яки каршы як полосага очып чыккан өлкәннәр аркасында зыян күрә», – диде Артем Хохорин.

Президент Рөстәм Миңнеханов балаларның юллардагы иминлеге мәсьәләсенә аеруча игътибарны арттырырга кушты. «Балалар еш кына өлкәннәр өчен бик яхшы укытучы да булып тора. Аларның иминлеген тәэмин итү системалы рәвештә алып барылырга тиеш. Ниндидер тематик дәрес, тәрбия сәгатьләре белән генә чикләнмәскә кирәк. Монда массакүләм мәгълүмат чараларын да, социаль челтәрләрне дә җәлеп итәргә кирәк, махсус мобиль кушымталар да артык булмас», – диде Президент. Рөстәм Миңнеханов мәктәп балаларын ниндидер чараларга йөрткәндә дә транспортта куркынычсызлык мәсьәләләренә таләпләрне арттырырга кирәклеген искәртте.

Генерал Хохорин җәяүлеләрне таптату очракларына да аерым тукталды. Ел башыннан бирле республика юлларында җәяүлеләр катнашында 914 юл һәлакәте теркәлде. 857 кеше төрле дәрәҗәдәге тән җәрәхәтләре алган, 79 җәяүле үлгән. Узган ел республика юлларында 89 кешенең гомере өзелгән булган. «Бу фаҗигаләр, нигездә, җәяүлеләрнең кисәк кенә юлга йөгереп чыгуы, караңгы вакытта тиешле булмаган урыннан юл чыгуы аркасында килеп чыккан», – диде министр. Сәбәбе – ваемсызлык. Кулына телефон тотып, машина астына кереп баручы җәяүлеләр адым саен.

Федераль трассалардагы юл һәлакәтләрендә җәрәхәтләнүчеләр саны арткан. «Һәлакәтләр нигездә каршы як полосага чыгу аркасында килеп чыга. Моның өчен юлларны бүлүче киртәләр урнаштырырга, ике полосалы юлларны киңәйтергә кирәк. Узган ел федераль трассадагы 24 чакрым юлга бүлүче киртә урнаштырылды», – диде Артем Хохорин. Министр куркыныч урыннар дип Казан – Ульян, Казан – Малмыж юлларын телгә алды. Аварияләрнең юл билгеләре булмавы, тамгаларның күренмәве аркасында да килеп чыкканын әйтте.

Әмма төп җаваплылык юлга чыгучыларның үзләрендә. Утырышта «тимер ат» ияләрен әзерләүче автомәктәпләр бакчасына да таш атылды. Артем Хохорин сүзләренә караганда, Татарстанда аларның эшчәнлеге әле дә булса җитди контрольгә алынмаган. «Соңгы ике елда машина йөртү стажы ике елдан азрак булган йөртүчеләр катнашындагы юл һәлакәтләре саны кимеде. Шулай да аларны укыткан оешмаларга сораулар бар әле», – ди ул.

Эчке эшләр министрлыгы уздырган тикшерүләр барышында автомәктәпләрдә кагыйдә бозу очраклары күп ачыкланган, анда эшләгән 71 хезмәткәр административ җаваплылыкка тартылган. Республиканың автомәктәпләрендә белем алган булачак йөртүчеләрнең яртысы гына теория буенча имтиханны беренче тапкырдан тапшыра. Йөртү буенча сынауны исә биштән бере генә уңышлы уза. «Кайбер укучылар имтихан вакытында машина йөртергә өйрәнә генә әле», – ди Артем Хохорин.

Министр сүзләренә караганда, якын арада бу мәсьәләдә катгый чаралар күрелә башлаячак. Аерым алганда, киләсе елдан «Дәүләт хезмәтләре» порталында бердәм имтихан сервисы эшли башлаячак. Ул булачак машина йөртүчеләрнең имтиханны ни дәрәҗәдә үз белемнәренә таянып, намус белән тапшыруын контрольдә тотарга ярдәм итәчәк. Әлеге сервис машина йөртү таныклыгы алгандагы ришвәтчелек очракларын да кисәтер дип көтелә.

Президент Рөстәм Миңнеханов исә мотоциклда йөрүчеләргә карата да игътибарны арттырырга кушты. «Шаулыйлар, газга басалар, снаряд кебек очалар. Юлдагылар гына түгел, җәяүлеләр өчен дә куркынычны арттыралар», – диде ул.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Татарстан – алтынчы урында

Татарстан Россия төбәкләрендәге тормыш сыйфаты рейтингында алтынчы урынга чыккан. Стратегик инициативалар агентлыгы беренче тапкыр төзегән рейтингта Мәскәү, Төмән өлкәсе, Ханты-Манси автономияле округы, Югра, Санкт-Петербург алдагы урыннарга эләккән. Татарстаннан соң – Ямал-Ненец автономияле округы, Белгород өлкәсе, Чуашстан. Рейтинг һәр төбәктә кешеләр ихтыяҗларының ни дәрәҗәдә канәгатьләндерелүен бәяли, яхшырту таләп иткән өлкәләрне ачыклый. Стратегик инициативалар агентлыгы башлыгы Светлана Чупшева билгеләп үткәнчә, лидерлар сафына эләгү төбәкнең бай булуына бәйле түгел. Ник дигәндә, рейтинг төзелгәндә бюджет акчасы күләме түгел, бәлки дөрес идарә итү зур роль уйный.

Президент полкына китәләр

Армиягә көзге чакырылыш тәгәлләнә. Чакырылыш азагына калучылар арасыннан 10 егет Мәскәүдә легендар Президент полкында хезмәт итәчәк. Республиканың хәрби комиссары Сергей Погодин билгеләп үткәнчә, илебезнең беренче постында – Билгесез солдат кабере янында сакта тору, Кремльдә хезмәт итү – зур дәрәҗә. Президент полкына кандидатлар бик җентекләп сайлап алына. Аларның физик һәм психик сәламәтлеге тикшерелә. Биредә хезмәт итүче егетләрнең гәүдә озынлыгы 175 сантиметрдан ким булмаска тиеш.

Татарстан егетләре хезмәт итү урынына Казандагы җыелма пункттан җибәрелә. Юлга кузгалуны алар 3 тәүлеккә кадәр көтә. Шул вакыт эчендә булачак солдатлар хәрби частьлардагыга охшаш казармаларда яши. Бүлмәләр, егетләрне коронавирустан һәм ОРВИ йоктырудан саклау өчен, тәүлегенә өч тапкыр антисептиклар белән чистартыла.

tatarstan.ru

«Пушкин» белән – кинога

Россия фильмнарына билетларны «Пушкин картасы» белән сатып алырга мөмкин булачак. Бу хакта Премьер-министр Михаил Мишустин кинематографияне үстерү советы утырышында белдергән. Мондый мөмкинлек февраль аеннан пәйда булачак. Кинога билет алу өчен картадагы 2 мең сумга кадәрге акчаны тотарга мөмкин. Премьер-министр билгеләп үткәнчә, бу яшьләргә генә түгел, Россия киноиндустриясенә дә ярдәм булачак. «Безнең илдә 14–22 яшьлек 13 миллион чамасы кеше яши. Һәркайсына 2шәр меңнән 26 миллиард сум килеп чыга. Мондый акчага сыйфатлы, әйбәт фильмнар белән көндәшлек итәргә була», – дигән Мишустин.

Сүз уңаеннан, сентябрь аенда Татарстан «Пушкин картасы» белән билетлар саткан төбәкләр унлыгына эләккән иде.

Алты кеше гаепләнә

Республикада коронавирустан вакцинация узу буенча ялган белешмәләр бирү турында җинаять эше кузгатылган. Тикшерү идарәсенең матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, «Ялган документлар әзерләүгә, эшләүгә яки аларны әйләнештә йөртүгә ярдәм итү» статьясы буенча кузгатылган җинаять эшенә 6 кешенең катнашы бар. Тикшерүчеләр билгеләгәнчә, быел ноябрь аенда шуларның өчесе 3 кешегә вакцинация узу турында ялган белешмә биргән өчен 37,5 мең сум күләмендә ришвәт тапшыруда арадашчы булган. «Алар, акчаның бер өлешен үзләренә калдырып, калганын тагын бер кеше аша шәһәрнең медицина оешмасында эшләүче шәфкать туташына тапшырган. Әлеге медицина хезмәткәре, Прививка ясатучылар дәүләт реестры белән эшли белмәгәнлектән, хезмәттәшенә ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән. Монысы 10 мең сум бәрабәренә реестрга ялган мәгълүматлар керткән. Нәтиҗәдә кешеләр вакцинация узу турында ялган сертификатлар алган», – диелә хәбәрдә.

Эчке эшләр министрлыгыннан кисәтелгәнчә, ялган QR-кодтан файдаланучыларга 6 айга кадәр кулга алу яный. Ә инде ялган белешмә сатучылар, саклаучылар 1 елга кадәр ирегеннән мәхрүм ителергә мөмкин.

COVID-19

Роспотребнадзордан – бәйрәм «күчтәнәч»е

Татарстанда соңгы дүрт атна дәвамында коронавирус инфекциясе белән авыручылар саны кими. Әйтик, соңгы атнада андыйларның саны 18 процентка кимегән. Әмма моңа карап кына Татарстан халкына Яңа ел бүләге ясамаячаклар – QR-код куллануны гамәлдән чыгармаячаклар. Күмәк иммунитетка да декабрь азагына кадәр ирешеп булмаячак. Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе башлыгы Марина Патяшина һәм Татарстанның Сәламәтлек саклау министрлыгы баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов кайбер сорауларга ачыклык кертте.

Республикада коронавируска бәйле вазгыять ни хәлдә? Соңгы 3–4 атнада авыручылар саны кими. Татарстанда «омикрон» штаммы юк. Әлеге инфекция таралу алган илләрдән кайткан 144 кеше тикшерелгән. ОРВИ һәм грипп белән авыручылар саны күп: барлыгы 25634 кеше авырый, атна эчендә 66 очрак ачыкланган. Шуңа күрә белгечләр гриппка каршы да прививка кадатырга өнди. Республикага барлыгы 1 млн 16 мең доза вакцина кайтартылган.

Татарстан хастаханәләрендәге коронавируслы сырхаулар өчен ятаклар фондын 50 процентка киметкәннәр. Медицина оешмаларының бер өлеше элеккеге эш режимына күчкән. Әмма алар, вазгыять кискенләшсә, яңадан ярдәм күрсәтергә әзер.

Коронавируска каршы вакцина ясатучылар күпме? Республикада 2251612 кеше коронавируска каршы вакцина ясаткан. Шуларның 1857896сы икенче дозаны алган. Билгеле булганча, күмәк иммунитетка ирешү өчен тагын 300 меңләп кешенең прививка кадатуы кирәк. Күмәк иммунитет күрсәткечен (80 процент. – **Ред.**) декабрьгә кадәр ирешербез дип өметләнсәк тә, булмады. Хәзер гыйнварга булыр дип өметләнәләр. Шуңа күрә Яңа елга кадәр QR-код системасы гамәлдән чыгарылмаячак.

Сүз уңаеннан, Роспотребнадзор Яңа ел төнендә җәмәгать туклануы биналарының эшенә бәйле чикләүләргә карата кайбер «йомшартулар» әзерләде. Билгеле булганча, 30 октябрьдән башлап Татарстанда кафе-рестораннарга төнге 11дән иртәнге 6га кадәр эшләргә ярамый иде. 20 декабрьдән алып 10 гыйнварга кадәр алар төнге 1гә кадәр эшләячәк. Яңа ел төнендә исә иртәнге сәгать 3кә кадәр эшләргә рөхсәт ителә.

Транспортта QR-кодны тикшерү дәвам итәчәкме? Бу эш дәвам итәчәк. Әмма, әйтик, Яңа ел төнендә тикшерүне көчәйтү күздә тотылмый. QR-код системасы кертелгән беренче атнада 3 меңләп хокук бозу очрагы теркәлгән. Хәзер аларның саны 350гә калган. Барлыгы 19 мең берәмлек җәмәгать транспорты тикшерелгән һәм 17 мең кагыйдә бозучы ачыкланган. 133 очракта полициягә мөрәҗәгать иткәннәр. Хәзер пассажирлар агымы да үз күрсәткеченә кайта.

kzn.ru

Сүзгә-сүз

Владимир ПУТИН, Россия Президенты:

Әлбәттә, Яңа ел бәйрәмнәре – һәр гаилә тормышында зур вакыйга, очрашасы, аралашасы килә, ул һәрвакыт киләчәккә өмет уята. Бәйрәмсез булмый. Әмма киләчәгебез чыннан да бәхетле булсын өчен, белгечләрнең барлык киңәшләренә колак салырга һәм аларны үтәргә кирәк.

РОССИЯДӘ – ХӘМЕРГӘ МӨНӘСӘБӘТ

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге Россиядә яшәүчеләрдән аларның алкогольле эчемлекләргә булган мөнәсәбәтен белешкән. Сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, халыкның 31 проценты хәмерне бөтенләй кулланмавын, калган 69 проценты исә сирәк булса да эчкәнен әйткән.

ХАЛЫК ФИКЕРЕНЧӘ, ИҢ ПОПУЛЯР ИСЕРТКЕЧ ЭЧЕМЛЕКЛӘР

Аракы	59%
Сыра	48%
Шәраб	21%
Көмешкә	19%
Коньяк	15%

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Басудан – тәлинкәгә

Владимир Путин Стратегик инициативалар агентлыгының күзәтүчеләр советы утырышында икътисади үсеш министры Максим Решетниковка балалар туклануы комплексларын төзү турындагы мәсьәләне хәл итәргә әмер бирде. Президент сүзләре белән әйтсәк, «басудан – өстәлгә, өстәлдән – тәлинкәгә» арзанлы һәм сыйфатлы ризык китерү белән кызыксынган махсус комплекслар булырга, бизнес шундый комплексларны оештыруга атлыгып торырга тиеш.

Владимир Владимирович фикеренчә, эшмәкәрләр мондый эшкә бик теләп алыначак, чөнки «нәр адымда нәрсәдер төзәргә кирәк»: авыл хуҗалыгы предприятиесеннән башлап эшкәртү, хәтта пешерү белән дә шөгыльләнүче бизнесны күтәрергә туры киләчәк. Президентның бу идеясенә ике нигезе бар: беренчесе – азык-төлекне читтән сатып алып пешерә башласаң, кыйммәткә чыга, икенчесе – сыйфатсыз да була. Басуга орлык сибүдән башлап, тәлинкәгә аш булуга кадәр процессны бер бизнес түбәсе астына куып кертсәң, арзанлырак килеп чыгарга тиеш соңгы продукт. Арадашчылардан башка эшләсәң, күпкә арзанрак чыга чөнки. Газета хәбәрчесенең моны онпан ипи пешерү схемасында раслап та күрсәткәне бар. Ипине кибеттән сатып алуга караганда, үз мичеңдә пешерсәң, якынча 3–4 тапкыр арзанрак чыга. Әле соңгы көннәрдә генә без бер капчык югары сортлы он китерттек. Бер кило он бәясе – 30 сум. Бер кило оннан 3 кибет ипие пешерен була (он ипигә әйләнгәндә масса да, күләм дә арта – моны күпләр белми). Бер ипи бәясе хәзер безда 40 сумга якынлашып килә. Менә шуннан аңлашыла инде: бер кулдан икенче кулга йөри-йөри соңгы продуктның бәясе 300–400 процентка арта. Бу гаҗәп түгел, чөнки һәр кучештә продуктка салымнар өстәлә, һәр кул үзенә табыш алырга теләп, үз бәясен куя һәм башкалар, һәм башкалар...

Путин менә шул кулларны бергә генә калдырып, мәктәп тукланунын булса да арзанлырак һәм сыйфатлырак итәргә теләи. Аның әмере дә шундый (тәрҗемәсез бирик әле): «подумать о возможности совмещения этой задачи и сохранения инструментов борьбы с необоснованным повышением цен». Максим Решетников бу мәсьәләне ничек хәл итәр – анысы әлегә мәгълүм түгел, әмма газета хәбәрчесенең фаразы тискәре. Президентка ярый һәм килешә дә ул, чөнки тормыш прозасыннан ерак тора, шуңа да аның күп нәрсәне күреп бетерә алмавы табигый. Бер мәктәп өчен, хәтта бер район мәктәпләре өчен дә мондый комплексларны төзү гаҗәп кыйммәткә төшәчәк, шуңа күрә бизнес аңа алынмаячак, алынса, дәүләттән субсидияләр һәм дотацияләрне мул таләп итәчәк. Дәүләт ярдәме килеп кердеме, анда урлашулар, өстәп язулар һәм башка төрле кыеш-мыешлар башлана. Һәм, гомумән, су асты ташлары гаҗәп күп монда.

Президентның нияте яхшылыкта, билгеле. Идея өчен аны гаепләргә кирәкми. Бәяләрнең чүпрә кебек кабаруы илнең югары җитәкчелеген борчый икән, бу бик яхшы. Әле соңгы көннәрдә генә Президент тагын бер тапкыр кабатлады бит: бәяләр тышкы базарның һәм ил эчендәге объектив сәбәпләрнең басымы астында күтәрелә. Инфляция бөтен дөньяны дер селкетә хәзер. Кипрдан хәбәр итәләр: ике атна эчендә ипигә һәм сөткә бәя 15 процентка үсте, диләр. Азык-төлеккә планета буйлап бәяләр парадының бер объектив сәбәбе бар: корылык. Әмма бәхеткә дип әйтик инде: бу төп сәбәп түгел. Төп сәбәп энергия ресурсларының кыйммәтләнүенә килеп тоташа. Соңгысының кыйммәтләнүе акчаның артык күплегеннән. Дөнья тарихында ике куәтле дәүләтнең алтын акча кубәю сәбәпле җимерелә язып калулары билгеле. Акча күбәйдеме, бәяләр күтәрелә, бу котылгысыз. Артык акчаны инвестицияләргә дөрес итеп юнәлтсәң, әле инфляция ташкынын берникадәр кейләп булыр иде. Әйтик, азык-төлек бәяләре түбәнәйсен өчен инвестицияләрнең авыл хуҗалыгы техникасы, ашлама, яңа сортлы орлыклар һәм технологияләр җитештерүгә юнәлтелүе таләп ителә.

Әмма глобаль капитализмда мәсьәлә алай хәл ителми. Басылган акча фонд базарына китә. Арзан гына кыйммәттә йөргән компанияләрнең бәясе чүпрә кебек кабара. Безне кызыктыралар бит әле, моннан егерме еллар элек 5 доллар торган ай-ти компанияләрнең бәясе 200–300 тапкыр артты, шул чакта аларның акцияләрен сатып алсагыз, миллионер була идегез, диләр. Янәсе, дөрес итеп инвестицияләр ясый белмәгәнсез икән, хәерчелегең өчен үзең үпкәлә. Ул компанияләр нәрсә җитештерәләр? Берни дә җитештермиләр. Аларның чын кыйммәтләре бик түбән. Хөкүмәтләр ни өчен акча баса? Фонд базары җимерелмәсен өчен. Олигархлар байлыгы кимемәсен өчен. Социаль киеренкелек тумасын һәм шартлау булмасын өчен, акчаның бер өлешен халыкка да өләшергә туры килә, әлбәттә. Менә шул өләшенгән акча инфляция дигән нәрсәне алга этәрә дә инде. Инфляция арткан саен, социаль ярдәмне көчәйтми булмый, ярдәм арткан саен, бәяләр үсә. Аның ярдәме дигәне дә бит әле күпчелек очракта ташламалы кредитларга кайтып кала. Кайсы өлкәгә өстенлекле кредит бирәсең, шул өлкәдә бәяләр күперә. Хәзерге вакытта ул, мәсәлән, төзелеш өлкәсе. Автомобиль сәүдәсе. Ягулыкка, техникага, сәнәгать товарларына бәяләр ике урынлы саннарда үсә икән, азык-төлек өлкәсе нишләргә тиеш? «Необоснованный рост цен» дигән вазгыятькә котылгысыз рәвештә килеп керергә тиеш. Азык-төлек бәясенең күтәрелүенә каршы бездә ничек көрәшергә җыеналар? Авыл хуҗалыгы министрлыгы һәм Икътисади үсеш министрлыгы чит илдән дуңгыз һәм сыер итен пошлинасыз кертү турында сөйләшүләр дигән сүзләр укыйм мин аңлыкларда. Бу бит инде – үзеңдә җитештерүне үтерү, азык-төлек бизнесын бөлдерү дигән сүз.

Менә шуңа күрә Владимир Владимировичның акыллы идеясе тормышка ашуына шикләнәм мин. 2014–2015 елларда бездә нинди кампания шаулады әле? Дөрес, импортны алыштыру дип йөрәксендек. Бездә аны ничек итеп «алыштырдылар»? Кәгазьдә зур планнар төзелде. Әмма үз продукциябезне җитештерү өчен уңай шартлар тудыру юнәлешендә берни дә эшләнмәде диярлек. Хәзер күрәбез: авыл хуҗалыгы предприятиеләре чаң суга, 2022 елда иткә бәя күтәреләчәк, чөнки Кытайдан аминокислоталар китерелми башлады, диләр. Китмәсә, чит илдән сатып алына торган терлек азыгы өстәмәләренә бәяләр дә күтәрелгән.

Бу юлларның авторы, ит проблемасын хәл итәбез дип, мәктәпләрдә куян һәм дуңгыз асрап азапланган елларны да хәтерли әле. 1982 елда Азык-төлек программасы кабул ителгәч, ит комбинатына терлек илткән машиналарның шәһәрдән авылга кайтып төпп кабатланып да онытмады.

Бәяләрнең бу ашкынуы глобаль системаның ахырына якынлашуын күрсәтә. Менә бу атна дәвамында төп базарларга караган илләрнең кубесендә Үзәк банкларның утырышы булды. Финансчылар акча басуны туктату турында килешергә азапланды. Англия банкы төп ставканы печтек кенә күтәрде. АКШ ФРС киләсе елга күтәрергә вәгъдә итте. Акча күп булса, система җимерелә, аны киметсәң, шулай ук җимерелә. Вазгыять хәзер шундый. Шул сәбәпле мәктәп ашханәсе масштабында гына булса да бәяләр төшерергә азаплану – тормышка ашмаслык эш ул. Бер бизнес та ул идеяга капмастыр, мөгаен.

АКЧА САНАГАННЫ ЯРАТА

Татарстан икътисады узган ел белән чагыштырганда 3,8 процентка үскән. Бу һәм башка саннарның уңай якка үзгәрүен Президент Рөстәм Миңнеханов икътисадның «җанлана башлавы» дип бәяләде. Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә финансчылар республикада акчаның каян килеп, кая китүе турында хисап тотты. Җыелышта Россия финанс министры Антон Силуанов та катнашты.

tatarstan.ru

Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, агымдагы ел йомгаклары буенча, республиканың тулай төбәк продукты күләмендә үсеш узган елдагыга карата 103,8 процент (3,2 триллион сум), сәнәгатьтә җитештерү индексы – 108,3 процент (3,7 триллион сум), төзелештә – 103,1 процент, ваклап сату әйләнешендә үсеш 106,2 процент дәрәҗәсендә көтелә. «Бу күрсәткечләр – пандемиянең бик авыр чорыннан соң икътисадның җанлана башлавы нәтиҗәсе», – диде Рөстәм Миңнеханов. Ул катлаулы чорда бизнеска, эш урыннарын саклап калуга бик зур ярдәм күрсәткән өчен ил җитәкчелегенә рәхмәт белдерде. Шул ук вакытта әлегә тулысынча аякка баса алмаган предприятиеләр дә бар. Статистика мәгълүматларына караганда, оешмаларның 23 проценты зыянга эшли.

Татарстанның үз керемнәре 333 миллиард сум дәрәҗәсендә бәяләнә. Федераль программаларны исәпкә алганда – 414 миллиард сум. Рөстәм Миңнеханов басым ясап әйткәнчә, чыгым вәкаләтләрен үтәү өчен икътисадның, бюджет керемнәренең уңай динамикасын саклап калу мөһим. Шулай ук зыянга эшләүче оешмаларның эшчәнлеген торгызу, хезмәт хакын «күләгә»дән чыгару, бурычны (бүгенгә – 7,9 миллиард сум) кимету буенча эшләүне дәвам иттерергә кирәк. Ел башыннан бирле бурыч күләме 859 миллион сумга кимегән.

Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, Татарстанның тупланма бюджеты чыгымнары 416 миллиард сум тәшкил итә. Быел республика бюджет буенча барлык йөкләмәләрне үтте. Чыгымнарның өчтән бер өлеше чамасы хезмәт хакын түләүгә китә. «Быел илкүләм проектлар чараларын гамәлгә ашыруга 34,1 миллиард сум тотыла. Шуның 25,4 миллиард сумы – федераль бюджеттән, 8,7 миллиард сумы – республика бюджетыннан», – диде Президент. Ул шулай ук 2022 елга республика бюджеты кабул ителүен, аның шактый ук кирәнкеле булуын искә төшерде. Дефицит күләме – 24 миллиард сум. Аны үз мөмкинлекләребез хисабына капларга туры киләчәк.

Ул барлык категорияләрдәге җир кишәрлекләренә дәүләт кадастр бәяләвен үткәрү мәсьәләсенә дә тукталды. Бу эшне 2022 елның октябрь башына кадәр төгәлләргә кушты. Президент киләсе елның республикада Цифрлаштыру елы буларак игълан ителәчәген дә искәртте. «Финанс органнары республиканың цифрлы үзгәрешләрендә актив катнашырга тиеш», – дип өстәде Рөстәм Миңнеханов.

Салым органнарының эш йомгаклары турында Федераль салым хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе башлыгы Марат Сафиуллин сөйләп үтте. Аның әйтүенчә, быел казнага 1,1 триллион сумнан артыграк акча керү көтелә. Узган ел белән генә түгел, пандемиягә кадәрге 2019 ел белән чагыштырганда да күбрәк бу. Салымнарның 70 проценты исә федераль бюджетка китә. Идарә башлыгы әйтүенчә, бизнесның күпме акча эшләвенә турыдан-туры бәйле салымнар күләме дә арткан. Бу хәл икътисадның терелешен раслый. Шул ук вакытта мөлкәткә салым күләме үскән.

Финанс министры Радик Гайзатуллин тупланма бюджетны үтәү йомгаклары турында сөйләде. Тупланма бюджетта салым һәм салым булмаган керем күләме 333 миллиард сум тәшкил итәчәк. Республика бюджетына 278,1 миллиард сум керачәк. Җирле бюджетларга – 54,9 миллиард. Ә инде республика тупланма бюджеты чыгымнары 415,9 миллиард сум тәшкил итәчәк.

Россия финанс министры Антон Силуанов, үз чыгышында, финанслар белән идарә итүнең сыйфаты буенча Татарстанның алдынгы сафларда баруын билгеләп үтте. «Системаның эшләве, бик төгәл корылуы турында сөйли бу. Татарстан – икътисади үсеш, инвестицияләр күләгеннән караганда, иң алдынгы төбәкләрнең берсе. Бирегә безә керемнәрнең ничек үсүен, сәнәгатьтә җитештерү күләменең, ваклап сату өлкәсендә товар әйләнешенең нинди булуын күреп торабыз. Болар икътисади үсешнең тагын да зуррак булачагы турында сөйли», – диде федераль министр.

Федераль министр өч ел дәвамында Илкүләм иминлек фондыннан икътисадка 2,5 триллион сум күләмендә акча тотыласын әйтте. Шул исәптән «Мәскәү – Казан» М12 юлын төзүгә. «Мәскәү – Казан» – безнең төп төзелеш. Бу юлны алга таба Екатеринбургка кадәр салачакбыз. Юл төзү кыйммәтләнүгә, озынлыгын арттыру, киңәйтүгә карамастан, барысы да вакытында эшләнәчәк», – дип ышандырды ул. Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, әлеге проектны гамәлгә ашыру республика үсешенә уңай йогынты ясаячак.

gossov.tatarstan.ru

БЕРЛӘШТЕРҮЧЕ КҮПЕРЛӘР

Йорт нигезе нык булсын өчен, һәр кирпечнең үз урынында булуы кирәк. Дуслык күперен төзегәндә дә шул ук кагыйдәгә таянасы. Һәрхәлдә, Татарстанның Халыклар дуслыгы йорты аны истә тотып эш итә. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да шулай дип мактады үзләрен. Республикада яшәүче милләтләр Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын ничек озата? Җыелышып, шул хакта сөйләштеләр.

Татарстан халыклары ассамблеясы советының бу елга соңгы утырышы узды.

Башкарган эшкә – рәхмәт, иң активларга – бүләк, советның яңа әгъзаларын алкышлау. Чарада Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, ассамблея советы җитәкчесе Фәрит Мөхәммәтшин елга йомгак ясады. Ә ел, мәгълүм сәбәпләр аркасында, җиңелләрдән булмады.

– Коронавирус, эшебезгә үзгәрешләр кертсә дә, аны туктатмады. Аз эшләмәдек. Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы ахырына якынлаша. Ассамблея аңа бәйле чараларда да катнашты, федераль, дәүләтара дәрәҗәдәге чараларда да чыгыш ясады. Барлыгы 6 меңнән артык чара үтте, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Ассамблея республикада милләтара мөнәсәбәтләрне саклауга саллы өлеш кертә, республикада яшәүче халыкларны берләштерә. Безнең команда ул – 249 милли-иҗтимагый берләшмә. Дуслык һәм бердәмлеккә керткән өлешегезнең бәһасе юк. Моны күңел кушканга, намус белән эшлисез.

Фәрит Мөхәммәтшин чарада катнашучыларга Татарстан Президенты сәламен һәм котлау сүзләрен дә җиткерде, республиканың иминлеге һәм социаль-икътисади үсеш өчен милләтара татулык һәм тынычлыкның төп нигез булып торуын билгеләп үтте.

– Бу сүзләрнең халыклы турында тагын да әйтеп торырга кирәкме икән? Минемчә, бирегә утырып һәр кеше аларның рас булуын аңлый. Узара мөнәсәбәтләребездә аз гына салкынлык, аз гына аңлашылмаучылык була икән, нинди үсеш турында сөйли алабыз? – диде парламент җитәкчесе. – Республиканың үзенчәлеге дә шул бит: төрле дин һәм милләтләрнең үзара ышанычлы аралаша алуы. Безнең максат – Татарстанда яшәүче төрле халыкларның бердәмлеген ныгыту. Ә ассамблея вәкилләре – милләтләр арасындагы берләштерүче күперләр ул. Дистә еллар эчендә республикадагы милли сәясәтне гамәлгә ашыру өлкәсендә мәктәп белән бергә милләтара татулык кебек катлаулы һәм мөһим мәсьәләләрне җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итә, этномәдәни тормышны җанландыра алдык. Күпмилләтле халкыбызның ышанычы эшебезнең төп нигезе булып тора.

Башкарган эшләрдән тыш, Фәрит Мөхәммәтшин Казанның күпмилләтле якшәмбе мәктәбенең эшчәнлегенә аерым тукталды. Ул быел үзенең 30 еллыгын билгеләп үтте. Аның җитәкчесе – Майя Хухунашвилины Татарстанда белмәгән кеше дә юктыр, мөгаен. Фәрит Мөхәммәтшин аның эшен күркәм һәм мөһим дип атады. «Әле дә бер очрак исемдә. Классның оешуын йөргәндә, бер милләт вәкиленә: «Сез бит ул кадәр күп түгел», – дигән идем. Халык аз буламы инде ул? Мондый мәсьәләләрне дә хәл итеп киләбез, республикада туган телләрне саклау һәм аларны киләчәк буынга тапшыру өчен шартлар тудырылуына чын күңелдән шатмын. Бу – һәр халык өчен да бәяләп бетергесез байлык», – дип, истәлекләрә дә бирелде ул.

Бу көнне ассамблейә шактый иштәде дә әле. Ассамблея Советы составына керү теләген якутларның милли-мәдәни берләшмәсе һәм тува милли-мәдәни автономиясенең «Алантон» җирле оешмасы белдерде. Аннан кала Әгерҗе, Лаеш, Саба, Балык Бистәсе районнарында ассамблеяның вәкилләрен булдыру турында карар кабул ителде. Шулай итеп, алар хәзер республиканың 33 районында бар.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Соңгы утырыш 24 декабрьдә узачак

Алтынчы чакырылыш Дәүләт Советының егерме сигезенче утырышы 24 декабрьдә үткәреләчәк. Парламент Президиумы утырышында шундый карар кабул ителде. Депутатлар 17 мәсьәләне, шул исәптән 4 республика һәм 9 федераль закон проектын карап тикшерергә ниятли.

Моннан тыш депутатлар Татарстан Югары Суды Рәисе Илгиз Гыйлаҗевнең республикада җәмәгать юстициясе эшчәнлеге турындагы чыгышын тыңлаячак. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин республика парламентының агымдагы елдагы эше турында сөйләячәк.

Президиум утырышында «Салым салуның автоматлаштырылган гади системасы» махсус салым режимын кертү буенча эксперимент үткәрүгә бәйле федераль закон проектлары каралды һәм хупланды. Эксперимент киләсе елның 1 июленнән илнең 4 субъектында үткәреләчәк. Мәскәү, Мәскәү һәм Калуга өлкәләре, Татарстан пилот төбәкләргә әйләнә.

Дәүләт Советы депутаты Эдуард Шәрәфиев тәкъдим иткән «Бөек Ватан сугышы чорында зыян күргән балаларга социаль ярдәм чаралары турында» федераль закон проектын исә киләсе утырышның көн тәртибенә кертмәскә карар кылдылар. «Закон бик зур иҗтимагый һәм социаль әһәмияткә ия, – дип басым ясап әйтте Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин. – Без Эдуард Шәрәфиевнең башлангычын хуплыйбыз. Әмма закон проектын эшләп җиткерергә кирәк. Сугыш чоры балаларына социаль ярдәм чаралары аларның һәркайсына бер үк төрле булырга тиеш».

Исегезгә төшерәбез: «Татарстан Дәүләт Советы сугыш чоры балалары статусын билгеләү һәм аларга социаль ярдәм чаралары күздә тоту балачыгы белән Дәүләт Думасына мөрәҗәгать иткән иде инде. Бирегә сүз сугыш елларында туган яки шушы чорда балигълык яшенә җитмәгән кешеләр турында бара. Республика парламенты тәкъдиме Дәүләт Думасы утырышында каралды, әмма федераль депутатлар тарафыннан инкарь ителде. Шуңа да карамастан, депутатларга әлеге категориядәге кешеләргә ярдәм итү үтенече белән мөрәҗәгать итүчеләр кимеми.

Республика парламентындагы фикеренчә, мондый кешеләрнең статусы федераль дәрәҗәдә билгеләнергә тиеш. Илнең төрле төбәкләрендә яшәүче сугыш чоры балаларының хокукларын тигезләү өчен кирәк бу. Дәүләт Советы депутатлары әлеге мәсьәләгә февраль аенда кире әйләнеп кайтырга ниятли. Россия Хөкүмәте исеменә мөрәҗәгать әзерләү ихтималы да бар.

Тынычлык һәм иминлек булсын

20 декабрь – Россия Иминлек органнары хезмәткәрләре көне. Һөнәри бәйрәмнәре белән аларны газета аша Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин котлады.

«Иминлек органнары һәрвакыт дәүләт идарәсе системасының мөһим өлеше булып торды, – диелә котлауда. – Ил мәнфәгатьләрен яклау, конституцион төзелешнең какшамаслыгын, Россиянең мәстәкыйльлеген һәм территориаль бөтенлеген, җәмгыятьтә тотрыклылыкны саклау сезнең өчен изге бурыч булып тора. Героик үткәнебезнең иң яхшы үрнәкләрендә тәрбияләнгән иминлек органнары хезмәткәрләренең алга таба да, хезмәт бурычына тугры калып, бик күп буыннарның традицияләрен дәвам иттерәчәгенә ышанам. Бу көнне иминлек органнары ветераннарына аерым рәхмәт сүзләре ирештерәсем килә. Алар яшь хезмәткәрләрнең чын профессионаллар булып өлгерүенә саллы өлеш кертә, бай тәҗрибәсе белән уртаклаша, һәлак булганнарның гаиләләренә төрле яклап ярдәм күрсәтә. Сезгә һәм якыннарыгызга нык сәламәтлек, шатлык-бәхетләр, озын гомер телим!»

КАДЕРЛЕБЕЗ ИДЕ...

Югалту

Бөтен нәрсәгә күнегәсең кебек. Хәтта үлемгә дә. Юк, алай түгел икән. Үлемгә күнегеп булмый. Редакциянең якын дусты, журналист Зимфира Гыйльметдинованың вафаты бигрәк тә үкенечле булды. Төпле киңәш бирер, ярдәм итәр, әллә нинди идеяләр уйлап чыгарып, аны башкарып та чыгар… Әнә шундый кеше арабыздан китте.

Соңгы юлга озатырга килүчеләрне күздән кичерәсең дә, күпме кешегә игелек кылганын күреп, хәйран каласың. Яшь язучылар, шагыйрьләр, журналистлар, артистлар – кемнәр генә юк иде. Һәм һәркем аны үзенеке итеп күрә. Гамил Нур: «Танылган тамада арабыздан китте», – дип яза. Хак сүзләр бит. Күпме мәҗлесләрне алып барды, күпме концертлар оештырды. Аны, режиссер иде, дип әйтүчеләр дә булды. Анысы да дөрес. Зимфира Гыйльметдинова «Ватаным Татарстан» газетасының 100 еллык юбилеенның да сценарий авторы, режиссеры булды. Кичәбез шулкадәр зәвыклы, затлы булып истә калды.

Саллы журналист иде. Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Илшат Әминов шулай диде:

– Бу хәлгә түзеп булмый инде, атна саен кеше җирлибез. Теге атнада «Казанские ведомости» журналисты Алексей Красновны җирләдек. Аннан алда 45 яшьлек бер дустымны җирләдем. Һаман шул чир алып китә. 60–70 яшьлекләрдән соң 40–50 яшьлекләргә тотынды. Йөрәк түзми, шулкадәр талантлы, үзенчәлекле кешеләр китә. Зимфира да шундый. Ул – татар телен үстерүдә күп эшләр башкарган кеше. Әле коллегалар белән дә сөйләшеп тордык: мәдәният темасына саф татар телендә язган сирәкләрнең берсе иде. Алар күп калмады. Ул мэриягә күчкәч, урамнарга татар рухы керер дип уйлаган идек. Булмады шул… Алып китә дә алып китә. Чынлап әйтәм, минем дә йөрәкнең түземлеге бетә. Яшь, матур, талантлы кешеләр киткән вакытта берничек тә түзеп булмый. Без аны бик ярата идек. Сезгә дә сүзем бар: үзегезне саклагыз! Үзебезне үзебез сакламасак, беркем дә сакламый.

Холкының үзенчәлеген Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла да атады. Ул аны «татар рухының моторы» диде:

– Үзе дә актив иде һәм безне дә тынычлыкта калдырмады. Мэриягә эшкә күчкәч тә нинди проектлар уйлап табып, гел шалтыратып торды. Мостай Кәримнең «Аусам иде бәйгеләрдә янып үлгән аргамак кебек» дигән шигыре бар. Эшләп торган җирдән янып үлде инде ул. Әле беркөнне генә «Сөйли торган материя» кичәсенә чакырып шалтыратты. «Үзең кайда соң син?» – дим. «Хастаханәдә шул әле», – ди. «Тынычлап дәвалан инде алайса, борчылма», – дим. Юк, ул тынычлап ята торган кеше түгел иде. Аның өлешенә зур миссия йөкләнде – Казаныбызга татар рухын кертүдә ул зур эшләр башкарырга тиеш иде. Кызганыч, кеше ниятли, язмышның – үз законнары. Бу безнең барыбызга да көтелмәгән авыр хәбәр булды. Зимфира турында озак сөйләп була, мин аның белән 2000 нче еллардан бирле аралаштым. Һәрвакыт аның принципиальлегенә, туры сүзлелегенә хәйран кала идем. Андый кешеләр бик сирәк була. Дуслары берәр кыек адым ясаса, монафикъланса, мәсләгенә хыянәт итсә, ул алар белән араны өзәргә дә күп сорамый иде. Моны сез барыгыз да беләсез. Аның арабыздан китүе әле озак еллар күңелебезне сызландырып торыр.

Бусы – Казан башкарма комитеты рәисе урынбасары Гүзәл Сәгыйтова сүзләре:

«Зимфира апаны бик күпләр яратканын белә идем. Ләкин шушы кадәр кешенең аны кадерләгәнен-хөрмәтләгәнен күз алдына да китермәгәнмен. Һәр җирдә үз эзен, үз сүзен калдыра алган матур киңкырлы шәхес. Ул бу урында да үзен тапкан кебек иде. Беренче көннәрдә үк үзе дә шулай дигән иде. Кызганыч, башкарма комитетта ул бары тик ике ай гына эшләп калды. Ул килгәч, мин шундый җиңел сулаган идем. Без бит икебез дә бер көнне туганбыз – 13 мартта. Ул һәрвакыт, без бертуганнар, дип әйтә иде. Ул безгә эшкә килгәч, шуны аңладым: тыштан бик үк охшап бетмәсәк тә, эчтән шулкадәр охшаганбыз икән. Ут иде ул! Ялкын иде! Зимфира апаны эштә без бик көттек. Терелеп чыкса, өстәлен чәчәкләр куеп, матур итеп каршы алырбыз дип, кызлар белән планнар да корган идек. Матур ниятләребез тормышка ашмады…»

Мамадыштан артист Сәлим Мифтахов белән бергә җитәкләп, Казанга алып килгәннәрен, туксанынчы елларда гастрольләр белән Себергә чаклы җиткәннәрен искә алды якын дусларының берсе, драматург Данил Салихов:

– Атна ярым элек син, безнең янга Кече Битаманга килеп, кычкырып әйтмәсәң дә, Рәмзия апаң һәм минем белән хушлашып киттең. Соңгы тапкыр каен себеркеләре белән чабынып киттең. «Китмә, тагын бер кич кун», – дисәк тә, икенче көнне китеп бардың. Мәңгелеккә дә китеп бардың. Зимфира дустым, кайда гына эшләсәң дә, һәрвакытта да эшеңне җиренә җиткереп эшләдең. Нәрсәгә генә алынсаң да, син шул урынның кешесе идең. Җырлый идең, бии идең, кирәк икән, яза идең, кирәк булса, тозлап-борычлап дөресен әйтә торган идең. Күңел тула… Хуш, бәхил бул, акыллым, хуш, бәгырькәем, хуш, сеңлем, оҗмах көтсен сине!

«Сәхнә», «Идел» журналлары, татар филармониясе… Эш урыннарын саный китсәң, шактый алар. Һәркайсында, безнең кеше иде, дип искә алалар, игелекле эшләрен санап китәләр. Туганнарына, авылдашларына да мәрхәмәтле, игелекле ул.

Авыл балаларын җыеп, Казанга алып килүләре, чишмә урынын төзекләндерүләре турында авылдашы, журналист Раушания Миңнуллина сөйләде:

– Питрәч районының Ленино-Кокушкино авылында үссә дә, ул үз авылын – Теләче районының Балыклы авылын күбрәк ярата иде кебек. Ул «Без – Сафиулла бабай онықлары» дип туганнарын җыеп торучы иде. Туганнарын гына түгел, авылны да. Без аның Татарстан күләмендә эшләгән эшләрен беләбез, ә менә бәләкәй генә авыл өчен эшләгән күпме эшләре бар! Берничә ел элек 8 Март алдыннан концерт оештырып, авыл өчен зур вакыйга ясады. Ураза аенда авыл чишмәсе янында ифтар оештырдык, җәмәгать белән намаз укыдык. Авылыбызда Сабантуйлар үтми иде, иганәчеләр табып, артистлар чакырып, балалар Сабан туен оештырды. Авыл балаларына Теләчедән автобус белешеп, Казанга экскурсиягә алып килде, үз акчасына сыйлап, аларга бәйрәм ясады. Хәзер авыл, дәррәү кубып, Зимфира башлаган ул бәйрәмнәрне үткәрә…

Кешене кадерләп, үзенә кадер ала иде. Татарстанның халык артисты Фердинант Сәлахов якын дусты хакында әнә шулай диде:

– Зимфира Мамадыштан килгәннән соң сигез ел минем бригадада эшләде. Сәхнәдә без аның белән дуэтлар җырладык. Филармониядә ул сигез ел безнең матбугат бүлеген җитәкләде. Директор Кадим Нуруллин: «Безнең филармониядә ул тынычлык күгәрчене кебек эшләде», – ди. Ул журналистлар белән эшләде. Берәүне дә рәнҗетергә теләмим – журналистлар белән эшләү бик катлаулы, бик четерекле характерлылар. Ул аларны җайлый белә иде. Данил «дустыбыз» диде, Зимфира ул – бик күп гаиләләрнең кадерле кешесе. Ул кешене кадерләп үзенә кадер ала белде. Үзе эшләргә тиешле урынны да тапты, әмма… Саклап та карадык, үзе дә бик сакланды. Монда бөтен нәрсә килешенгән, диде… Безнең Ходай белән генә килешү юк иде…

vk.com

Зимфира үзенчә китте. Көтмәгәндә, эшләп торган җирдән, сискәндереп, йөрәкне сыздырып. Үзеннән соң тау хәтле эш, яратып дәшә торган «наным» сүзен калдырып. Ул үзенең эчке дөньясына бик сирәкләрне генә кертә иде. Күңел капкасы ачылып, серләре дөньяга чыга калса, моны кешегә әйтмә, үзеңдә калсын дип колагыңны борып куярга да онытмый иде.

Соңгы тапкыр сөйләшкәндә, яңадан хастаханәгә керергә әзерләнүен әйтте. Озак сөйләштек. Чир, вакцина турында да сүз булды. Шунысын әйтәсе килә: хәзер ишетелгәли торган, «алай итмәгән булса, болай булыр иде» дигән сүзләрне Зимфира өнәмәс иде.

Сүзне кыска тотарга яраткан Зимфира ул юлы телефонын куярга теләмәде кебек. Соңгы җөмләсе әле дә колакта яңгырап тора: «Эш күп дип зарланмагыз. Егәр барда, исәнлек барда яратып эшләргә кирәк. Эшләр идем әле, дәрман юк…» Искә алуыбыз рухын шат кылсын иде.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме сигезенче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме сигезенче утырышын 2021 елның 24 декабрендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2021 елның 17 декабре
№ 1242-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме сигезенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме сигезенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 250-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
2. «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 253-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
3. «Татарстан Республикасы Җир кодексының 21 статьясына үзгәреш кертү турында» 254-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
4. «Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 251-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында.
6. 2022 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы турында.
7. 2022 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планы турында.
8. Татарстан Республикасында җәмәгать юстициясе эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Югары Суды Рәисе мәгълүматы.
9. «Салым салуның автоматлаштырылган гадиләштерелгән системасы» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент үткәрү турында» 20281-8 номерлы федераль закон проекты хакында.
10. «Салым салуның автоматлаштырылган гадиләштерелгән системасы» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент үткәрелүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 20492-8 номерлы федераль закон проекты хакында.
11. «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 50 һәм 56 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 20283-8 номерлы федераль закон проекты хакында («Салым салуның автоматлаштырылган гадиләштерелгән системасы» махсус салым режимын кулланудан керемнәрне бүлү нормативларын билгеләү хакында).
12. «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 28408-8 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясе субъектлары дәүләт бурычы һәм муниципаль бурыч составында Россия Федерациясе субъектларының дәүләт гарантияләре һәм муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләрне әлеге мәсьәләләрне бюджет системасының барлык дәрәҗәдәге бюджетлары өчен бердәм хокукый җайга салуны билгеләү максатларында төгәлләштерү өлешендә).
13. «Россия Федерациясендә исәп-хисап башкарганда контроль-касса техникасын куллану турында» Федераль законның 2 һәм 4^2 статьяларына һәм «Ваклап сату базарлары турында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 33099-8 номерлы федераль закон проекты турында (контроль-касса техникасын куллану тәртибе хакында).
14. «Экологик экспертиза турында» Федераль законның 11 һәм 14 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 11901-8 номерлы федераль закон проекты турында (яңа техникага, технологиягә техник документация проектларына дәүләт экологик экспертизасы ясау өлешендә).
15. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 20280-8 номерлы федераль закон проекты турында (сәүдә урыны бирелгән затларның контроль-касса техникасын кулланмавына бәйле рәвештә базар белән идарә итүче компаниягә җаваплылык билгеләү хакында).
16. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 27.10 һәм 27.11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 20308-8 номерлы федераль закон проекты турында (административ хокук бозулар турында эшләр буенча эш башкарганда тартып алынган законсыз әзерләнгән агачны реализацияләү, утильләштерү яисә юкка чыгару тәртибен билгеләү өлешендә).
17. 2021 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турында мәгълүмат.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2021 елның 17 декабре
№ 1243-VI ДС

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлегe һәм татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен шагыйрь, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» җәмәгать оешмасы (Иҗат берлеге) әгъзасы **Гатауллин** Рәдиф Кәшфулла улы; мәдәниятне һәм сәнгатьне үстерүдәге казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Бәхетле балачак» балалар үзәге» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры **Ишкузина** Светлана Владимировна; театр сәнгатен үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен «Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты, әйдәүче сәхнә остасы **Сафин** Нуриәхмәт Вәлиәхмәт улы; халык сәламәтлеген саклау өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары **Яркәева** Фәридә Фатыйх кызы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Мәдәниятне үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы «Энергетик» мәдәният сарае» муниципаль бюджет учреждениесенең үзешчән сәнгать коллективы җитәкчесе **Вәлиуллина** Әлфия Халис кызы; Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Актаныш район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе рәссам-декораторы **Фатыйхов** Таһир Гайса улы; мәдәниятне һәм сәнгатьне үстерүгә зур өлеш кертүләре, күпьеллык намуслы хезмәтләре һәм актив иҗтимагый эшчәнлекләре өчен «Заман» нәшрияты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Гарифҗанов** Марат Фәрит улы; «Бәрмәнчек» керәшен дәүләт фольклор ансамбле» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең сәхнәгә куючы режиссеры **Макаров** Геннадий Михайлович; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Гомәров» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы **Гомәров** Илшат Нургали улы; «Кулон Агро» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Мифтахов** Рафикъ Вәли улы; күпьеллык намуслы хезмәте һәм туристлык өлкәсен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Сәфәр» туристлык фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Муллина** Светлана Михайловна; финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Хисап палатасы контроль-ревизия идарәсенең төбәк контроле бүлеге башлыгы – инспекторы **Насыров** Рафаэль Ренат улы; мәгълүмат технологияләрен үстерүгә һәм камилләштерүгә өлеш кертүе, дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәгълүмат технологияләре, элемтә һәм мәгълүматны саклау идарәсе башлыгы **Огородников** Алексей Игоревич; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм театр сәнгатен үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен «К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Нәҗмиев** Нуретдин Гыйльмехан улы Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башлыгы урынбасары, район советы рәисе урынбасары **Белова** Галина Владимировна, «ТАТЭЛЕКТРОМОНТАЖ» акционерлык җәмгыятенең Түбән Кама монтажлау идарәсе башлыгы **Гатин** Мәхмүт Мингалим улы, Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе **Гущин** Иван Николаевич, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 5 номерлы районара инспекциясе 1 номерлы камераль тикшерүләр бүлеге башлыгы урынбасары Лысенко Татьяна Евгеньевна, «М.М. Громов исемендәге очучылык-тикшеренү институты» акционерлык җәмгыятенең Очучылык эше буенча очучы-сынаучылар мәктәбе башлыгы урынбасары – очучы-сынаучысы **Мөхәммәтгәрәев** Венер Мансур улы, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесе баш фәнни хезмәткәре **Сөләйманова** Гүзәл Фуат кызы, «Казан шәһәренең «Уңайлы торак» компанияләр төркеме» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Хөснетдинов** Эмиль Наил улы, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе технологик тәэминат бүлеге башлыгы **Чихирев** Олег Владимирович, «Шәһри Казан» музейлар комплексы» Казан шәһәре муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең фәнни-экспозиция бүлеге әйдәүче методисты **Шаһиева** Розалина Гомәр кызы, «Эссен Продакшн АГ» акционерлык җәмгыяте генераль директорының корпоратив сәясәт, дәүләт хакимияте органнары белән хезмәттәшлек, җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтәләр буенча урынбасары **Шәйморатов** Илшат Габделхәй улы, «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының авылара китапханәсе» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Яфизова** Гөлфия Зарифулла кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 5 номерлы районара инспекциясе башлыгы **Баишев** Марат Әнвәр улына; Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 3 номерлы районара инспекциясе башлыгы **Галиуллина** Зөлфия Илдар кызына; Федераль салым хезмәтенең Казан шәһәре Мәскәү районы буенча инспекциясе 1 номерлы бурычларны җайга салу бүлеге башлыгы **Фәхретдинова** Эльвира Гаил кызына; «Б.И. Тихомиров исемендәге «Казан Гипрониавиапром» акционерлык җәмгыяте баш бухгалтеры **Захватова** Татьяна Александровнага; Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторы **Колодников** Сергей Евгеньевичка **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Акыл үсеше ягыннан артта калган балалар өчен Дербышки балалар йорты-интернаты» дәүләт казна учреждениесе хезмәткәрләре: тәрбияче **Волкова** Ирина Александровнага, тәрбияче **Иванова** Ольга Юрьевнага **«Татарстан Республикасының атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Әхмәров** Илдар Гаваз улына, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Юность» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Гыйлаҗетдинов** Хәмзә Хәниф улына, «Татарстан Республикасының Хоккей федерациясе» иҗтимагый оешмасы башкарма директоры **Голубев** Кирилл Витальевичка, «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Буревестник» ябык йөзү бассейны» укыту-спорт комплексының спорт буенча өлкән инспекторы **Карымов** Виктор Васильевичка, Татарстан Республикасының «Чаңгы ярышлары һәм биатлон федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы эксперт советы әгъзасы **Рожков** Геннадий Николаевичка, «Фехтование буенча олимпия резервы республика спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесе директорының спорт эше буенча урынбасары **Шәйхетдинова** Лиля Илдар кызына **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Белдерү

ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ ПО СОГЛАСОВАНИЮ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА

Кадастровым инженером Осиповым Алексеем Федоровичем (г. Казань, ул. Журналистов, д. 30, кв. 108, e-mail: geodezy@rambler.ru, тел.: +7 9600559524, СНИЛС 047-159-072-63, квалификационный аттестат 16-15-843; реестр кадастровых инженеров № 36006; СРО АКИ «Поволжье» № 1145 протокол № 18/2016 от 22.11.2016 г.) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:20:220103:94, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Зеленодольский муниципальный район, Мизиновское сельское поселение, с. Мизиново, ул. Школьная, дом 29, выполняются кадастровые работы по уточнению местоположения границы земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Пуртов Николай Анатольевич (420032, Республика Татарстан (Татарстан), г. Казань, ул. Краснококшайская, д. 127, кв. 42, тел.: +7 9869225650).

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится по адресу: Республика Татарстан, Зеленодольский муниципальный район, Мизиновское сельское поселение, с. Мизиново, ул. Школьная, дом 29, 18 января 2022 г. в 10 часов 00 минут.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: г. Казань, ул. Журналистов, д. 30, кв. 108, e-mail: geodezy@rambler.ru, тел.: +7 9600559524.

Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана, и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 18 декабря 2021 г. по 17 января 2022 г. по адресу: г. Казань, ул. Журналистов, д. 30, кв. 108, e-mail: geodezy@rambler.ru, тел.: +7 9600559524.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ: 16:20:220103:93, расположенный по адресу: Республика Татарстан, Зеленодольский муниципальный район, МО «пгт Нижние Вязовые», с. Мизиново, ул. Школьная, 29А; 16:20:220103:5, расположенный по адресу: Республика Татарстан (Татарстан), Зеленодольский муниципальный район, с. Мизиново, ул. Школьная, д. 28.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 г. № 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ ПО СОГЛАСОВАНИЮ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА

Кадастровым инженером Осиповым Алексеем Федоровичем (г. Казань, ул. Журналистов, д. 30, кв. 108, e-mail: geodezy@rambler.ru, тел.: +7 9600559524, СНИЛС 047-159-072-63, квалификационный аттестат 16-15-843; реестр кадастровых инженеров № 36006; СРО АКИ «Поволжье» № 1145 протокол № 18/2016 от 22.11.2016 г.) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:170107:1, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Приволжский район, сдт «Поиск», участок № 90, выполняются кадастровые работы по уточнению местоположения границы земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Колоколова Татьяна Николаевна (Республика Татарстан (Татарстан), г. Зеленодольск, ул. Паратская, д. 13, кв. 111, тел.: +7 9274455713).

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Приволжский район, сдт «Поиск», участок № 90, 19 января 2022 г. в 10 часов 00 минут.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: г. Казань, ул. Журналистов, д. 30, кв. 108, e-mail: geodezy@rambler.ru, тел.: +7 9600559524.

Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана, и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 18 декабря 2021 г. по 17 января 2022 г. по адресу: г. Казань, ул. Журналистов, д. 30, кв. 108, e-mail: geodezy@rambler.ru, тел.: +7 9600559524.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ: 16:50:170107:125, расположенный по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Приволжский район, сдт «Поиск», участок 91.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 г. № 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

Спорт

Беренче медаль

Франциядә биатлон буенча Дөнья кубогы ярышларының дүртенче этабы башланды. Анда чыгыш ясаучы спортчылар арасында татар егете, Самара өлкәсенең Камышлы районында туып-үскән Эдуард Латыйпов та бар. Беренче өч этап нәтиҗәләре буенча, ул Россия җыелма командасындагы биатлончылар арасында иң яхшысы булып танылды. Җомга көнне исә шәхси ярышта беренче медален яулады.

Узган сезонны Эдуард Латыйпов шәхси зачетта 18 нче урында тәмамлады. Татар спортчысы иптәшләре белән эстафета ярышларында 4 медаль яулады. Шуның берсе аеруча кадерле. Россиянең эстафета командасы 10 гыйнвар көнне Германиядәге Оберхоф каласында узган ярышта финишка беренче булып килде. Бу вакыйгага аерым тукталуның сәбәбе дә бар. Ник дигәндә, безнекеләрнең инде 43 ярыш дәвамында медаль ота алганы юк иде! Шәхси ярышларда Эдуард бердәнбер медален март аенда яулады. Швециядә 15 чакрым арага узышуда финишка икенче булып килде.

Быел ул ике медаль отарга өлгерде. Швециядә һәм Австриядә узган ике ярышта да иптәшләре белән өченче урынны алды. Җомга көнне шәхси ярышта да бәхет елмайды. Дөнья кубогының Франциядә башланган дүртенче этабында ул 10 чакрымга спринт узышында финишка икенче булып килде. Эдуард Латыйпов беренче урынны алган Норвегия биатлончысыннан нибары 7,2 секундка калышты. Шулай итеп, Эдуард гомуми зачетта бишенче урынга күтәрелде. Атуны яхшырта алса, нәтиҗәләр тагын да яхшырак булачак. Ярыш башланыр алдыннан «ВТ» хәбәрчесе Эдуардның әтисе Радмил Латыйпов белән сөйләшкән иде.

– Быел яхшырак чыгыш ясый. Тәҗрибәсе дә артты, шөгыльләнүнең дә файдасы бар. Шәхси ярышларда да уңыш булыр дип көтәбез. Сезон әле башланды гына, – диде 27 яшьлек биатлончының әтисе. – «Медаль янәшәдә генә, алырга кирәк», – дип киңәш бирәм. Көче җитәрлек. Россия спортчылары арасында беренче булуы комачау итмиме? Мин дә шулай дип сорадым. «Юк, мин үз чыгышым турында гына уйлыйм. Ә командада без барыбыз да тигез», – диде.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

vk.com

Белми калмагыз!

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 Язылу квитанциясен безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

Җиңүче жирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, жирәбә 20 гыйнвар көнне үткәреләчәк.

Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ

- ✓ мини-тракторлар;
- ✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
- ✓ җир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Советская урамы, 42А.

ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ



1 **ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ**

2 **ОНЛАЙН:** **vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.**

Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре

П2435 **атнага бер, җомга килә** 465 сум

П2409 **Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә** 1000,92 сум

Реклама 16+

РУХИ АЗЫК ӘЗЛӘП... РЕСТОРАНГА!

Мәдәни тукталыш

Узган гасырның 30 нчы еллары башында ТАССР җитәкчелеге Казанда эшләүче нәшриятларны, газета һәм журнал редакцияләрен, типографияне бер урынга җыярга карар кыла. Шулай итеп, Бауман урамы үзәгендә зур ачык китап рәвешендә төзелгән Матбугат йорты барлыкка килә.

Ул төзелүгә, биредә республиканың китап нәшрияты, Татарстанның Язучылар берлеге идарәсе һәм шәһәрдәге иң зур китап кибете тату гына «яши» башлый. Шушында ук Габдулла Тукай исемендәге иҗат клубы очрашулары да уза.

Бүген әлеге тарихи бинаны «Ногай» кунакханә комплексы буларак беләләр, ләкин әүвәлге китап һәм матбугат йорты, рәвешен үзгәртсә дә, рухын югалтмый. Бинада «Китап club» рестораны ачылу да әнә шул хакта сөйли.

Татар китапларын да, сый-хөрмәтне дә сыендырачак әлеге әдәби ресторанда Татарстан китап нәшрияты басмалары, газета-журналлар белән таныша алачак. Әлеге үзенчәлекле ресторанның ишекләре инде ачык, һәм әлегә биредә 500ләп басма табарга мөмкин. Теләгән һәркемнең аларны өстәл янына утырып уку, ошатса, сатып алу мөмкинлеге бар.

– Мондый үзенчәлекле ресторан ачу безнең күптәнге хыялыбыз иде. Уңышлы гына эшләп килүче әдәби кафе турында ишетмәгән кеше калмагандыр инде. Хәзер исә татар китапларын иркенрәк урында, тарихи үзәкләрдә табып булачак. Биредә аларны ашыкмый гына, өстәл янында тәмле чәй эчә-эчә сайлап була. Алай гына да түгел, «Китап club» ресторанын танышу, очрашулар урыны итәсе килә. Безнең язучылар да мондый урынның кирәклеген берничә кат искәртте. Һәм менә, ниһаять, Яңа ел алдыннан без мондый урынны булдырдык, – диде ресторанның тантаналы ачылышында «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев.

«Ногай» кунакханә комплексының генераль директоры Виталий Большаков сүзләренчә, әлеге әдәби ресторан кешеләрдә китап тарихына, татар китапларына карата булган кызыксынуны арттырачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Матбугат йортыннан кунакханә ясаган вакытта без әлеге бинаның тарихи үзенчәлеген саклап калырга тырыштык. «Ногай» кунакханә комплексында китап кибете дә эшләде, Габдулла Тукай иҗат клубы исемен йөртә торган зал да бар. Татар китабы тарихына бәйле экспонатларны да күз карасы кебек саклыйбыз. Бүген менә «Татмедиа» һәм Татарстан китап нәшрияты белән берлектә шушы тарихны, татар китапларын киң җәмәгатьчелеккә җиткерүнең тагын бер юлын таптык, – дип сөйләде ул.

Инде әйтелгәнчә, «Китап club» рестораны киләчәктә татар интеллигенциясе өчен очрашу урыны да булачак. Биредә яңа татар китапларын тәкъдим итү кичәләре, язучы һәм шагыйрьләр белән очрашулар, тематик чаралар да уздырырга ниятлиләр.

– Бер ел элек без Декабристлар урамында урнашкан «Татмедиа» бинасында «Әдәби кафе» ачтык. Шуннан бирле шактый тәҗрибә тупладык, кешегә мондый форматның чын мәгънәсендә кызыклы булуына инандык. Ул шулкадәр танылды – татар матбугатын, китапларын сөючеләрнең яраткан урынына әйләнде. Һәм менә бүген Казанның нәкъ үзәгендә сезне әдәби ресторанда сәламлибез. Ул да «Әдәби кафе»дан ким булмас дип ышанам, – диде Татарстан китап нәшрияты җитәкчесе Илдар Сәгъдәтшин.

Әдәби ресторанның ачылу тантанасында татар язучылары һәм шагыйрьләре дә катнашты. Без исә «Безнең мирас» журналы баш мөхәррире, язучы Ләбиб Лерон белән аның яшь чакларын искә алдык:

– Студент чакта бу бинага еш йөри идек без. Редакцияләр, Татарстан Язучылар берлеге шушында урнашкан иде. Ә беренче катында Казандагы иң зур китап кибете эшләде. Университетка якын булгач, китап алыр өчен җәяүләп гел шушында йөрдек. Бүген менә бирегә шул заман мохите кайта кебек. Җәй көне әдәби ресторан каршында шигъри кичәләр, әдәби бәйрәмнәр уздырылса, тагын да яхшы, халыкка күңелле булыр иде, – дип сөйләде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

АПА БЕЛӘН СЕҢЕЛ

Гаилә учагы

Кышка аяк басар алдыннан без ел саен Балык Бистәсе районындагы Кече Әшнәк авылына кунакка кайтабыз. Сәбәбе дә бар: нәни апабызның туган көне. Нәни апа дигәнебез – каенанамның сеңлесе Мәсхүдә апа. Рәшидә әниебез авылда җәй көне генә яшәгәнлектән, элегрәк, әби-бабайдан калган йортны кышка әзерләп, бикләп килү йоласы да иде ул. Хәзер инде Мәсхүдә апа үзе дә, озын кышкы кичләрдә ялгыз утырудан кыенсынып, сәламәтлеге дә азрак какшау сәбәпле, район үзәгендәге кызлары Лилия гаиләсендә кыш чыгуны кулайрак күрә. Шулай итеп, ике нигез берьюлы ак карга күмелеп кала.

Әмма сүзем ул хакта түгел. Картлык көннәрендә ике әбекәйнең бер-берсенә терәк булып, аларга карап, бала-оныкларның бер бөтен булып яшәүләре сокландыра мине. Әни белән нәни апаның язмышлары да бертөрлерәк булды. Икесенең дә ирләрен фаҗигә йолып алды: Рәхмәтулла абый 50 яше тулган көннәрдә урман кисүендә агач астында калды, әти машинага тапталып үлде. Менә шул вакытларда нәни апага ярдәм бигрәк тә кирәк булды. Хатын-кыз ирсез калдым дип тормый бит инде ул, бигрәк тә авыл җирендә. Сыерын да асрый, бер көтү сарык, кош-корт та ишегалдында чемченеп йөри. Шулай булмый хәл дә юк. Ике кызны укытырга да, башлыкүзле итәргә дә кирәк иде. Апасының өч улы иң зур ярдәмче булды аның өчен. Йорт-җирне дә караштылар, колхоз бүлеп биргән җирдә печәнен дә чаптылар, бәрәңгене дә алыштылар. Хәтерлим әле: кайчакларда бәрәңге бакчасында 20шәр кеше була идек. Олыраклар казый, бала-чага җыя, көчлерәкләре капчык белән ташып урнаштыра… Эшкә ярамый дигәннәре дә тик тормый: капкалап алырга дип, бакча уртасында өстәл ясый, Мәсхүдә апа чәй чыгара. Эш түгел, бәйрәм иде ул. Яшьрәк чакта, эшләү сәбәпле, әбиләренә Казанга кайта-китә йөрергә туры килгәч, үз балаларыбыз да җәйләрен Мәсхүдә апа йортына сыену ягын карыйлар иде. Башта кечләрен Лилия апалары белән йөрсәләр, аннан үзләре генә клубка чыккаладылар. Безнең күңел тыныч иде. Тик менә нәни апалары-ның гына төн йокыларын качырган булып чыктылар. «Ул-бу булмасын дип, бик курка идем. Балалар ишегалдына кергәнче, бер тәрәзәдән икенчесенә йөреп үтә иде вакытым. Аннан, кыенсынмасыннар дип, тиз генә урыныма кереп ята идем. Янәсе, мин күптән йоклыйм», – дип, соңыннан гына сөйләде. Бу халәтен безгә түгел, кызларга да сиздермәгән.

Бер елдан нәни апаның – 80, ике елдан әнинең 90 яшьлек юбилеен бәйрәм итәргә җыенабыз.

Нык иде нәни апа заманында. Авылда кайчандыр бригадир булып эшләгән. Олыгая төшкәч, мәктәптә җыештыручы, пешерүче булды. Авылдагы бар бала-чага аның өчен үзенеке иде. Ир-атлар белән бер рәткә басып эшләр, эһ тә итмәс иде ул. Гел-гел кешегә ялынып йөреп булмый дип, кулына чүкеч-балта тотарга да өйрәнде. Берзаман шулай без кайткан төшкә өйалды ясап куеп, барыбызны да шаккатырды.

Әни дә, пенсиягә чыккач, җәй буена авылда яшәргә өйрәнеп китте. Кирәкми, азапланып йөрмә дип үгетли-үгетли, үзебез үк бакча тутырып бәрәңге утыртабыз. Ул яшелчәсе тагын! Бер карыш җирне дә буш калдырасы түгел, рөхсәт юк. Авыл психологиясе. Кызлар тормыш корып, оныклар пәйда булгач, авылга йөрүләребез генә азрак чикләнде. Әби-бабай янына дип, ял көннәрендә үз оныкларыбыз килә башлады. Хәер, бер дә аптырарлык булмады үзе, кирәк булса, без югында Мәсхүдә апаның кызлары, кияүләре ярдәмнән калдырмый әниебезне. Нәни апа да, үзе әйтмешли, көненә әллә ничә катлый төп нигезне.

Рәхәт тә, кызык та гомер кичерә әбиләребез. Газеталар укыйлар, телевизор карыйлар, берәр нәрсәгә фикерләре капма-каршы булса, бәхәсләшеп китәргә, ул гына да түгел, үпкәләшеп алырга да күп сорамыйлар. Сүздән сүз чыгып, бер кирәкмәгәнгә килеп чыга инде андый хәлләр. Дуслашулары да тиз була. Әле генә табадан төшкән берәр тәмле ризык белән бергәләп чәй эчү барысын да хәл итә. Шулай булмыйни! Күптән ике генә бөртек калган бит инде алар. Энеләре Фәйзрахман 21 яшендә үк салкын тиеп үлеп киткән, Азия исемле туганнары да яшьли бакыйлыкка күчте. Аларны бик сагыналар, гел искә алып сөйләшәләр, догаларыннан калдырмыйлар.

Кыш – әбиләр өчен сагыну чоры. Икесендә дә кесә телефоны. Чынлап та, исемен җисеменә туры китереп, алар аны кесәдә генә йөртә. Алай-болай бер-берсенең шалтыратканын ишетми калсалар, борчылуларына чик-чама булмый чөнки. «Ике тапкыр шалтыраттым. Мәсхүдә телефонын алмый. Авырып китмәгәндер инде. Телефоны никтер эшләми…» Мондый вакытта балалар, оныклар ярдәмгә килә. Кем аша булса да, әбиләр бер-берсен табышалар, исән-сау булуларын белгәч, бик шатланышалар. Бу безнең өчен дә бик кирәк. Әбиләр шундый туганчыл булгач, башкалар белән дә элемтәне өзәргә юл куймыйлар. Әвәрә килеп, бәйрәм итеп ятуларыбыз да – шуның бер дәлиле.

Җиргә ак кар яуган саен, Әшнәктәге йортлар күз алдына килә. Сукмаклар күмелгәндер, эзләр югалгандыр инде. Нишлисең, бик күп авыл йортлары шундый язмышка дучар. Җәйгә булса да, капкалар ачылсын иде әле, сукмакларга чирәм үсмәсен, әбиләребез эзләрен яңартып торсыннар иде. Нәни апаның туган көненә кайткан саен, без әнә шундый теләкләр белән китәбез.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7387 данә
Гомуми тираж – 17167 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 385

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+